ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

# Татарстан Республикасында пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендәге законнарны мониторинглау йомгаклары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты рәисе А.В. Тыгинның мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы түбәндәгеләрне билгеләп үтә.

Пассажирлар йөртү халык өчен мөһим һәм кирәкле хезмәтләрнең берсе булып тора. Татарстан Республикасында пассажир транспорты җир өсте, су, тимер юл, һава транспорты һәм урамнан тыш транспорт белән күрсәтелгән. Җәмәгать транспортының массакүләм төре булып автомобиль һәм шәһәр электр транспорты тора, анда пассажирлар йөртү өлеше барлык төр пассажирлар йөртүнең 97 процентын тәшкил итә.

Автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне төрле милек рәвешендәге 45 пассажирлар йөртүче башкара, шул исәптән 15 эре автотранспорт предприятиесе. Маршрут челтәре даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның 165 муниципальара маршрутыннан тора. 2021 елда әлеге транспорт төре белән 237,2 млн пассажир йөртелде, шул исәптән шәһәр эчендәге маршрутлар буенча – 216,5 млн пассажир, шәһәр яны маршрутлары буенча – 16,8 млн пассажир, шәһәрара маршрутлар буенча – 3,9 млн пассажир.

2022 елның I яртыеллыгы ахырына шәһәр электр транспорты предприятиеләренең хәрәкәт составының уртача исемлек саны 472 берәмлекне тәшкил итте, шул исәптән 249 трамвай, 208 троллейбус, 15 метрополитен поезды.

Шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртү 38 маршрут буенча башкарыла. 2021 елда шәһәр электр транспортында 88,4 млн пассажир йөртелде. 2021 елда шәһәр электр транспорты предприятиеләрендә пассажирлар йөртү әйләнеше 419,2 млн пассажир-километр тәшкил итте.

Пассажирлар йөртү тармагы, икътисадның башка тармаклары белән беррәттән, эчке һәм тышкы факторлар йогынтысына дучар. Коронавирус пандемиясе белән барлыкка килгән күп кенә чикләүләр, шулай ук геополитик хәлнең тотрыксызлыгы һәм кертелгән икътисадый санкцияләр транспорт

системасына да йогынты ясады. Катлаулы финанс хәлендә, беренче чиратта, автомобильдә пассажирлар йөртү предприятиеләре булды, бу пассажирлар ташкынының кимүе, ягулыкның, хәрәкәт составының, комплектлау кирәк-яраклары бәяләре артуы һәм башкалар белән аңлатыла. Беренче планга өзлексез пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны саклап калу һәм халык өчен кулай дәрәҗәдә тарифларны арттырмау мәсьәләләре чыкты, бу федераль дәрәҗәдә дә, региональ дәрәҗәдә дә дәүләт ярдәме чаралары комплексын кабул итүне таләп итте.

Шулай 2021 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә 843,8 млн сум күләмендә субвенцияләр бирелде, 2022 елда күрсәтелгән максатларга 1642,6 млн сум каралган.

Агымдагы елда республика бюджетыннан түбәндәгеләргә акчалар бирелде:

яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау максатларында чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә пассажирлар йөртүчеләрнең алып бетерелмәгән керемнәрен каплауга 68,8 млн сум күләмендә;

пассажирлар йөртүчеләрнең пассажирларның персональ QR-кодлары булуын тикшерүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарын каплауга 16,8 млн сум күләмендә.

Шәһәр яны юлларында муниципаль маршрут челтәрен үстерү кысаларында авыл маршрутларын субсидияләү программасы дәвам иттерелде, аның буенча агымдагы елда 39 муниципаль берәмлек бюджетында чыгымнар күләме 300,7 млн сум (2021 елда 138,6 млн сум) тәшкил итте.

Икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү буенча дәүләт тарафыннан кабул ителгән чаралар пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның автомобильдә пассажирлар йөртү кебек социаль әһәмияткә ия төрен, шул ук вакытта халыкның аннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итеп һәм гражданнарның аерым категорияләре өчен ташламаларны саклап, чынбарлыкта саклап калырга мөмкинлек бирде. Әмма бүген тармакта барлыкка килгән вәзгыять, тулаем алганда, тармак эшчәнлегенең урта һәм озак сроклы перспективада нәтиҗәле финанс моделен булдыру буенча дәүләт дәрәҗәсендә концептуаль карарлар эшләүне таләп итә.

Әлеге тезис парламентарийлар адресына пассажирлар йөртүчеләрнең күпсанлы мөрәҗәгатьләрен исәпкә алып булдырылды, алар нигезендә һәм хокук куллану тәҗрибәсен анализлау максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак төзелеше һәм инфраструктура үсеше комитеты (алга таба шулай ук – Комитет) тарафыннан 2021 елның февралендә пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендәге законнарны мониторинглау турында карар кабул ителде.

Мониторинг барышында башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары, күзәтчелек органнары билгеләнгән эшчәнлек өлкәсе һәм компетенция чикләрендә катнашты. Мониторингка граждан җәмгыятенең билгеле хокук куллану тәҗрибәсенә ия булган төрле институтлары, Татарстан Республикасының эре пассажирлар йөртүчеләре, шулай ук Комитет каршында булдырылган Эксперт советы җәлеп ителде.

Мониторинг нәтиҗәләре автомобиль пассажир транспортының һәм шәһәр җир өсте электр транспортының проблемаларын һәм үсеш перспективаларын тикшерү өчен хокукый, оештыру һәм техник характердагы түбәндәге төп юнәлешләрне билгеләргә мөмкинлек бирде:

автомобиль пассажир транспорты, шәһәр җир өсте электр транспорты инфраструктурасын һәм паркын үстерүнең республика дәрәҗәсендә бердәм концепциясе булмавын;

икътисадый җайга салуның гамәлдәге институтларының, аерым алганда, тариф сәясәтенең камил булмавы аркасында инфраструктураны һәм хәрәкәт составын яңарту өчен транспорт предприятиеләренең үз инвестиция мөмкинлекләре булмавын;

шәһәрләрдә һәм шәһәр агломерацияләрендә гомуми файдаланудагы пассажир транспортының мобильлеге белән идарә итү һәм аның ролен күтәрү механизмнары камил булмавын (урам-юл челтәрендәге транспортны киметү максатында җәмәгать транспорты тукталышлары янында урнашкан парковкаларны үстерү, гомуми файдаланудагы пассажир транспортының маршрут челтәрен камилләштерү һ.б.);

транспорт предприятиеләренең машина йөртүчеләр белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин ителмәвен һәм аларны һөнәри әзерләү системасының җитәрлек дәрәҗәдә нәтиҗәле булмавын;

кирәгеннән артык транспортка ихтыяҗны һәм шәһәр урам-юл челтәрләренең артык күп булуына китерә торган шәһәр төзелеше һәм транспорт планлаштыруының, шул исәптән агломерация алымнарын кулланып, үзара бәйләнеше булмавын;

автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты инфраструктурасының һәм хәрәкәт составының үсеше халыкның мобиль булмаган төркемнәре (балалар коляскалары белән булган пассажирлар, инвалидлар һәм башкалар) өчен җитәрлек дәрәҗәдә булмавын.

Мониторинг барышында ачыкланган кайбер проблемалар «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 16 июлендәге 52-ТРЗ номерлы (җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны башкара

торган транспорт предприятиеләренә гражданнарның ташламалы категорияләрен йөртүгә бәйле рәвештә алынмаган керемнәрне каплау механизмын билгеләү өлешендә) һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 25 июлендәге 48-ТРЗ номерлы (Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны һәм мондый пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тәртибен оештыру өлкәсендә вәкаләтләрен актуальләштерү өлешендә) Татарстан Республикасы законнарында хәл ителде.

Гомумән алганда, мониторинг нәтиҗәләрен анализлау Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары белән берлектә пассажирлар йөртү өлкәсендәге вәзгыятьне өйрәнү эшен дәвам итү һәм халыкның транспорт хезмәтләреннән файдалану мөмкинлекләрен һәм аларга ихтыяҗларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән берләштерелгән закон чыгару һәм идарә итү карарларын эшләү зарурлыгын дәлилләде.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты рәисе А.В. Тыгин мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетына пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендәге законнарны мониторинглау эшен, шул исәптән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә чыгып, дәвам итәргә һәм, кирәк булганда, федераль законнарга һәм республика законнарына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдим итәргә:

3.1. Берничә муниципаль берәмлектәге транспорт планлаштыруы документларын килештерүне тәэмин итү һәм бердәм тариф системасын булдыру өчен җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр агломерацияләренең гомуми файдаланудагы транспорт системасы белән идарә итү вәкаләтләрен яңадан бүлү мәсьәләсен карарга.

3.2. Автомобиль пассажир транспортының һәм шәһәр җир өсте электр транспортының хәрәкәт составын модернизацияләүгә дәүләт ярдәменең нәтиҗәле механизмнарын эшләү (даими эшләүче механизмнар булдыру)

мәсьәләсен, шул исәптән дәүләти-хосусый партнерлык шартларында бюджеттан тыш чыганакларны җәлеп итеп, эшләргә.

3.3. Элек булган Татавтотранс предприятиесе мисалында автомобиль пассажир транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында халыкка транспорт хезмәте күрсәтү системасы белән бердәм идарә итү һәм аны финанслау үзәген төзү мәсьәләсен карарга.

4. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына тәкъдим итәргә:

4.1. Татарстан Республикасында халыкка нәтиҗәлерәк транспорт хезмәте күрсәтү моделен гамәлгә кертү максатларында Россия Федерациясенең башка субъектларында автомобиль пассажир транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруга анализ ясарга.

4.2. Гомуми файдаланудагы транспорт чаралары паркын яңарту буенча чаралар үткәргәндә, шул исәптән предприятиеләрнең үз акчаларын кулланып, халыкның мобиль булмаган төркемнәрен йөртү өчен җайлаштырылган транспорт чаралары өстенлеген исәпкә алырга.

4.3. Җир өсте җәмәгать пассажир транспортының хәрәкәт составын яңарту буенча чараларны гамәлгә ашыру өчен федераль программаларда актив катнашырга.

4.4. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән берлектә автомобиль пассажир транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты предприятиеләренә заманча транспорт чаралары паркын яңартуга һәм үстерүгә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары эшләргә.

4.5. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән берлектә транспорт предприятиеләре тарафыннан хәрәкәт составына өзлексез хезмәт күрсәтү өчен җиһазлар һәм комплектлау җайланмаларын кайтаруның логистик һәм житештерү чылбырларын җайга салу эшен дәвам итәргә.

4.6 Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә пассажирлар йөртү куркынычсызлыгын тәэмин итүче җаваплы машина йөртүчеләрне һәм белгечләрне һөнәри әзерләү һәм сайлап алу системасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләргә.

5. Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

5.1. Транспорт планлаштыруын халыкның транспорт ихтыяҗларына һәм түләү мөмкинлекләренә мәҗбүри периодик мониторинг ясау нигезендә шәһәр төзелеше планлаштыруы белән үзара бәйләнештә гамәлгә ашырырга.

5.2. Муниципаль берәмлектә социаль инфраструктураның төп объектларыннан транспорт белән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында халыкның мобиль булмаган төркемнәренә транспорт хезмәте күрсәтүнең яңа рәвешләрен үстерү мәсьәләсен эшләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 15 сентябре
№ 1553-VI ДС